| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

20.07.2023 г.Зеленодольск № 295

Татарстан Республикасы бюджетыннан «Коммерциячел булмаган оешманың һәм халык хакимияте органы – Татарстан Республикасы дәүләт (муниципаль) архивын комплектлау чыганагының иң яхшы архивы» республика конкурсында җиңүчеләрне акчалата бүләкләү өчен, финанс белән тәэмин итү чыганагы булып субсидияләр һәм (яки) максатчан билгеләнештәге башка бюджетара трансфертлар булып торган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү кагыйдәләре турында

«Зеленодольск муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» муниципаль учреждение җитәкчесе урынбасары Т.М. Ламбинаның Татарстан Республикасы бюджетыннан «Коммерциячел булмаган оешманың һәм халык хакимияте органы – Татарстан Республикасы дәүләт (муниципаль) архивын комплектлау чыганагының иң яхшы архивы» республика конкурсында җиңүчеләрне акчалата бүләкләү өчен, финанс белән тәэмин итү чыганагы булып субсидияләр һәм (яки) максатчан билгеләнештәге башка бюджетара трансфертлар булып торган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү кагыйдәләре турындамәгълүматын тыңлап фикер алышканнан соң, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 142 статьясы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды**:

1. Татарстан Республикасы бюджетыннан «Коммерциячел булмаган оешманың һәм халык хакимияте органы – Татарстан Республикасы дәүләт (муниципаль) архивын комплектлау чыганагының иң яхшы архивы» республика конкурсында җиңүчеләрне акчалата бүләкләү өчен, финанс белән тәэмин итү чыганагы булып субсидияләр һәм (яки) максатчан

билгеләнештәге башка бюджетара трансфертлар булып торган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү кагыйдәләрен 1 нче кушымтада каралганча расларга.

2. Әлеге карарның нигезләмәләре 2023 елга һәм 2024 һәм 2025 еллар план чорына кадәр бюджетларны төзегәндә, раслаганда һәм үтәгәндә барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре составындагы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

**Зеленодольск муниципаль районы**
**Башлыгы, Советы рәисе** **М. П. Афанасьев**

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ИНН 1648017831 КПП 164801001
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

1 нче кушымта
2023 елның 20 июленнән
295 номерлы Зеленодольск
муниципаль районы Советы
карарына

Татарстан Республикасы бюджетыннан «Коммерциячел булмаган оешманың һәм халык хакимияте органы – Татарстан Республикасы дәүләт (муниципаль) архивын комплектлау чыганагының иң яхшы архивы» республика конкурсында җиңүчеләрне акчалата бүләкләү өчен, финанс белән тәэмин итү чыганагы булып субсидияләр һәм (яки) максатчан билгеләнештәге башка бюджетара трансфертлар булып торган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү кагыйдәләре

1. Әлеге Кагыйдәләр Татарстан Республикасы бюджетыннан «Коммерциячел булмаган оешманың һәм халык хакимияте органы – Татарстан Республикасы дәүләт (муниципаль) архивын комплектлау чыганагының иң яхшы архивы» республика конкурсында җиңүчеләрне акчалата бүләкләү өчен, финанс белән тәэмин итү чыганагы булып субсидияләр һәм (яки) максатчан билгеләнештәге башка бюджетара трансфертлар булып торган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү максатларын, тәртибен һәм шартларын билгели(алга таба - башка бюджетара трансфертлар, җирлекләр).

2. Башка бюджетара трансфертлар «Коммерциячел булмаган оешманың һәм халык хакимияте органы – Татарстан Республикасы дәүләт (муниципаль) архивын комплектлау чыганагының иң яхшы архивы» республика конкурсында җиңүчеләрне акчалата бүләкләү өчен гамәлгә ашыру максатларында җирлекләр бюджетларына бирелә.

3. Башка бюджетара трансфертлар Татарстан Республикасы бюджетыннан «Коммерциячел булмаган оешманың һәм халык хакимияте органы – Татарстан Республикасы дәүләт (муниципаль) архивын комплектлау чыганагының иң яхшы архивы» республика конкурсында җиңүчеләрне акчалата бүләкләү өчен Зеленодольск муниципаль районы бюджетына бирелә торган башка бюджетара трансфертлар хисабына җирлекләр бюджетларына бирелә.

4. Башка бюджетара трансфертлар тиешле финанс елына һәм план чорына Зеленодольск муниципаль районы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм әлеге Кагыйдәләрнең 2 пунктында каралган максатларга билгеләнгән тәртиптә бирелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

5. Җирлекләр бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары булып түбәндәгеләр тора:

a) конкурсның җиңүчесе (җиңүчеләре) дип танылган авыл җирлеге (җирлекләре) булуы.

b) җирлекләрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 44 статьясында каралган җирле бюджетларга Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджетара трансфертлар бирүнең төп шартларын үтәве.

6. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына «Коммерциячел булмаган оешманың һәм халык хакимияте органы – Татарстан Республикасы дәүләт (муниципаль) архивын комплектлау чыганагының иң яхшы архивы» республика конкурсының конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсе расланган көннән алып, 10 эш көне эчендә, җирлекләрнең башкарма комитетлары түбәндәге документларны тапшыра:

Татарстан Республикасы Архив эше буенча Дәүләт комитеты боерыгы белән расланган форма буенча башка бюджетара трансфертлар бирү турында заявка;

башка бюджетара трансфертлар бирү турында заявкага кул куйган затның вәкаләтләрен раслый торган документ;

юридик затларның бердәм дәүләт реестрына акчалата бүләкләүләр алу турында документлар күчермәләре.

7. Җирлек бюджетына бирелә торган башка бюджетара трансфертлар күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$S = Psp / Dsp,$$

биредә:

S - җирлеккә башка бюджетара трансферт күләме, сум;

Psp - «Татарстан Республикасы муниципаль архивы комплектлау чыганагы-авыл җирлегенең җирле үзидарә органының иң яхшы архивы» номинациясе буенча конкурста җиңүчеләр дип танылган авыл җирлегенең җирле үзидарә органнарына акчалата бүләкләү күләме, сум;

Dsp - «Татарстан Республикасы муниципаль архивы комплектлау чыганагы-авыл җирлегенең җирле үзидарә органының иң яхшы архивы» номинациясе буенча конкурста җиңүчеләр дип танылган авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары саны,сум;

8. Җирлек бюджетлары арасында башка бюджетара трансфертларны бүлү Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының муниципаль хокукый акты белән раслана.

9. Җирлекнең Башкарма комитеты Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына Татарстан Республикасы Архив эше буенча Дәүләт комитеты билгеләгән формаларда һәм тәртиптә башка бюджетара трансфертлардан файдалану һәм башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткеченә ирешү турында хисап тапшыра.

Планлаштырылган чаралар үтәлмәгән очракта, хисаплылыкка аңлатма язуында аларның үтәлмәү сәбәпләре һәм җирлекнең Башкарма комитеты кабул иткән чаралар турында мәгълүмат булырга тиеш.

10. Башка бюджетара трансфертлардан файдалануның нәтиҗәлелеге күрсәткече булып «Коммерциячел булмаган оешманың һәм халык хакимияте

органының иң яхшы архивы – Татарстан Республикасы дәүләт (муниципаль) архивын комплектлау чыганагы» Республика конкурсы турында нигезләмәсенең 2.4 пунктындагы «а» пунктчасында күрсәтелгән архив документларын саклауның норматив шартларын тәэмин итү тора.

10. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына тапшырылган белешмәләрнең дөреслеге өчен җаваплылык җирлекнең Башкарма комитетына йөкләнә.

11. Башка бюджетара трансфертлар җирлек бюджетларына Башкарма комитеты тарафыннан тәкъдим ителә торган заявка нигезендә җирлекнең җирле бюджетларның үтәлешенә касса хезмәте күрсәтү өчен ачылган Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча Идарәсенең территориаль органнарының счетларына күчерелә.

12. Башка бюджетара трансфертлар бирү шартларын бозган очракта, тиешле акчалар Россия Федерациясе бюджет законнарында билгеләнгән тәртиптә, Зеленодольск муниципаль районы бюджеты кеременә күчерелергә тиеш.

13. Башка бюджетара трансфертлар бирелгән елдан соң киләсе елның 1 гыйнварына кулланылмаган башка бюджетара трансфертларның калган өлеше, Россия Федерациясе Бюджет кодексында билгеләнгән таләпләргә ярашлы рәвештә, Зеленодольск муниципаль районы бюджеты керемено кайтарылырга тиеш.

14. Башка бюджетара трансфертлар максатчан характерда була һәм, әлеге Кагыйдәләрнең 2 пунктында күрсәтелгәннәрдән тыш, башка максатларда файдаланыла алмый.

15. Башка бюджетара трансфертларны максатчан куллануны контрольдә тотуны, законнарга ярашлы рәвештә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты һәм муниципаль финанс контроле органнары гамәлгә ашыра.